**ГЛАВА УСАДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Усады, ул.Советская,41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСАД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Усад авылы,Совет ур.,41

Тел./факс: +7(84365) 73-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**29 октябрь 2019 ел** **№ 1**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлегенең Усад торак пунктларында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2019 елның 9 ноябрендә 10 сәгать 00 гә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә: Усад авылы, Мәктәп урамы, 47 йорт (Усад мәктәбе янында).

2. 2019 елның 9 ноябрендә 12 сәгать 00 гә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә: Усад авылы., Совет урамы, 24 йорт ( кибет янында).

3. 2019 елның 9 ноябрендә 14 сәгать 00 гә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә: Усад авылы, Төньяк урамы,2 йорт янында.

4.Усад авылы халкы исемлеге гражданнар җыенын үткәрү өчен территориаль билгеләр буенча бүленгән:

4.1. Беренче этап - Мәктәп, Яшьләр, Совет (38дән 78кә кадәр йортлар), Кояшлы, Якты, Яз урамнары.

4.2. Икенче этап - Яшел, Совет 1 нче тыкрыгы, Совет 2 нче тыкрыгы, Студентлар, Совет урамнары (1-53 йортлар, 2-36 йортлар).

4.3. Өченче этап - Сирен, Үзәк, Кыр, Юл, Бакча, Төньяк, Арбузов урамнары.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

Усад торак пунктында 2020 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлегенең Усад торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- вак таш сатып алу һәм Усад торак пунктында посёлок эчендәге юлларны ремонтлауга;

- Усад торак пунктында урам яктыртуы челтәрләрен төзү, ремонтлау һәм карап тотуга;

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көненнән алып 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе урынбасары,
Җирлек башлыгы урынбасары Д.В.Нигметзянова